Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XX-5**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 24 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында биләүләре коррупция хәвефе белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында

“Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында” Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 21 июлендәге 925 номерлы Указы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган “2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасының 1.2.5 пункты, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында” 2016 елның 23 апрелендәге X-4 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карарын һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган “2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру” муниципаль программасының 1.2.5 пункты исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында биләүләре коррупция хәвефе белән бәйле булган кушымта итеп бирелә торган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген расларга (алга таба – Исемлек).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затларына:

Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән муниципаль хезмәткәрләргә аларны эштән азат иткәндә “Коррупциягә каршы тору турында”2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсендә каралган чикләүләрне, бурычлар һәм җаваплылыкны аңлатырга;

әлеге карарны исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәткәрләргә җиткерергә.

3. Балык Бистәсе муниципаль район Советының ”Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында аларны биләү коррупция хәвефе белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2016 елның 16 ноябрендәге XIII-5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                                            И.Г.  Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның  24 июлендәге
XX-5 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында аларны биләү коррупция хәвефе белән бәйле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге**

1 бүлек. Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратындагы муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфасы:
Совет аппараты җитәкчесе.

2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфасы:
мөстәкыйль бүлек башлыгы.

3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары:
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары;

муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфасы:
бүлекнең баш белгече.

2 бүлек. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары:
Башкарма комитет җитәкчесе;
Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары:
мөстәкыйль бүлек башлыгы;
башкарма Комитет органы башлыгы.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары:
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары;
башкарма Комитет органы башлыгы урынбасары.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары:
Бүлекнең, башкарма Комитет органының баш белгече;
Бүлекнең, секторның, башкарма Комитет органының әйдәүче белгече.

3 бүлек. Җирле үзидарәнең башка органында, җирле үзидарәнең башка органы аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе;
җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары.
2. Муниципаль хезмәтнең төп вазыйфасы
мөстәкыйль бүлек башлыгы.
3. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфасы
мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары.
4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфасы
Бүлекнең әйдәүче белгече.